**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**АПАС ШӘҺӘР ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

18 март, 2022 ел №_96_

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм 2022 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2021 елның 29 ноябрендәге 384-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлеге Советы карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Апас шәһәр җирлеге Советының 2019 елның 8 ноябрендәге 214 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының «Апас шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 9 статьяның 3 пунктын төшереп калдырырга;

10 статьяның 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.Муниципаль эчке алынмалар Поселение бюджеты кытлыгын финанслау, Поселениенең бурыч йөкләмәләрен каплау, Поселения бюджеты счетларында калган акчаларны финанс ел дәвамында тулыландыру максатларында, шулай ук федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына бюджет кредитлары бирү тәртибендә каралган Татарстан Республикасы бюджетыннан Поселения бюджетына бюджет кредитлары бирү максатларында гамәлгә ашырыла.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм җирлекнең мәгълүмат стендларында халыкка чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны җирлек башлыгына йөкләргә.

**«Апас шәһәр тибындагы поселок»**
**Муниципаль берәмлек башлыгы**
**Апас шәһәр җирлеге Советы рәисе** **А.Г. Җиһаншин**